ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2019 г. Заинск № 620

**Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр алучы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең муниципаль финансларын социаль-икътисадый үстерү һәм савыктыру чараларын күздә тоткан килешүләр төзү тәртибе, сроклары һәм килешүләргә таләпләр турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.1 статьясы 6 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.9 статьясы 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасы (алга таба – финанс органы) 2020 елда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация алучы җирлек башкарма комитеты җитәкчесе белән Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең социаль-икътисадый үсеше һәм сәламәтләндерү чараларын күздә тоткан килешү (алга таба - килешү) төзергә хокуклы дип билгеләргә, ул түбәндәге тәртиптә имзалана:

килешүгә 2020 елда Татарстан Республикасы муниципаль район бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация (алга таба - дотация) алучы җирлек башкарма комитеты җитәкчесе кул куя һәм ул 2020 елның 1 февраленә кадәр финанс органына тапшырыла;

килешү финанс органы тарафыннан 2020 елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча имзалана.

2. Килешү 2020 елның 15 гыйнварына кадәр җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан финанс органына 2020 елда дотация алудан рәсми баш тарткан очракта төзелми.

3. Установить, что соглашение должно предусматривать: Бу килешү түбәндәгеләрне күздә тотарга тиеш дип билгеләргә:

кушымта нигезендә дотация алучы җирлекнең йөкләмәләре исемлеге буенча;

финанс органы килешүләрдән барлыкка килгән җирлек йөкләмәләренә кагылышлы дотация алучы җирлек башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тапшырыла торган документларны карарга һәм шушы документларга бәяләмә әзерләргә тиеш.

4. Дотация алучы җирлек башкарма комитеты җитәкчесенә әлеге карар кушымтасында каралган йөкләмәләрне үтәү турында 2021 елның 20 гыйнварына кадәр финанс органына хисап җибәрергә.

5. Җирлек тарафыннан каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык чаралары сыйфатында билгеләргә:

а) әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасы, 3 пункты белән - 2021 елга (2021 елга, 2022 һәм 2023 елларның план чорына) бюджет турында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган дотацияләр бүлүгә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла торган 2021 елга дотация күләмен 2021 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан да артмаган, ләкин 2021 елга җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан да артмаган күләмендә кимету;

б) әлеге карарга кушымтаның 2 пунктындагы «а» пунктчасы белән - (2021 елга һәм 2022- 2023 еллар план чорына) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган дотацияләр бүлүгә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла торган 2021 елга дотация күләмен кимету (2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына) күрсәтелгән җирлек тарафыннан җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыру күләмендә, 2021 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан да артмаган һәм 2020 елга җирлек бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисап күрсәткечләре буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 проценттан да артмаган өлеше күләмендә.

әлеге карарга кушымтаның 2 пунктындагы «а» пунктчасы белән - 2021 елга (2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына) бюджет турында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карары белән расланган дотацияләр бүлүгә үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла торган 2021 елга дотация күләмен кимету күрсәтелгән җирлек тарафыннан җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларына, сайлап куела торган вазыйфаи затларына, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыру күләмендә, 2021 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан да артмаган һәм 2020 елга җирлек бюджеты үтәлеше турында еллык хисап күрсәткечләре буенча җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 проценттан да артмаган өлеше күләмендә.

6. Дотация алучы җирлек:

җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең әлеге килешүгә кул куйган вәкаләтләре туктатылган очракта һәм 2020 елда җирлек башкарма комитетының башка затын (җирлек башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы) билгеләп куйган очракта, килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә;

әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында һәм 2 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен, 2020 елда җирлек тарафыннан мондый йөкләмәләрне үтәүгә комачаулаучы бәхәссез көч шартлары (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, җаваплылыктан азат ителә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне бүлү методикасы үзгәрүгә бәйле рәвештә 2020 елда шушы вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга субвенция күләме артуга бәйле рәвештә җирлекнең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре саны арткан очракта, әлеге карарга кушымтаның 2 пунктындагы «в» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

7. Финанс органына 2020 елның 1 февраленә кадәр дотация алучы җирлек башкарма комитеты җитәкчесе имзаланган килешүне тапшырмаган очракта, 2021 елга Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетын формалаштырганда (2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына) 2021 елга дотация күләме 2020елга, ә бюджетта Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр өлеше җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 50 процентыннан арткан җирлеккә карата 2021 елга дотация күләменең 10 процентына киметелә, финанс орган шулай ук 2020 елда Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы карарында каралган дотацияләрне 2020 елга (2020 елга һәм 2021 һәм 2021 еллар план чорына) дотацияләр күләменең 2020 елга (2021 һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына) бирүне килешү имзаланган көнгә кадәр туктатып тора.

8. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районының финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Зәй муниципаль район
Башкарма комитетының
10.12. 2019 ел № 620

карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең муниципаль финансларын социаль-икътисадый үстерү һәм савыктыру чаралары каралган килешүгә кертелергә тиешле Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотация алучы җирлек йөкләмәләре исемлеге**

1. Җирлекнең дотациялелек дәрәҗәсен киметүгә һәм җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру йөкләмәләре түбәндәгеләрне күз алдында тота:

в) 2020 елга җирлек бюджетын үтәү йомгаклары буенча, 2019 елгы үтәлеш дәрәҗәсе белән чагыштырганда (процентларда), җирлек бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре үсешен тәэмин итү;

г) җирлек башкарма комитеты җитәкчесенең финанс органына түбәндәгеләрне килештерүгә юллавы:

җирлек бюджеты проектының 2021 елга (2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына) төп параметрлары (керемнәр төрләре буенча керемнәр; чыгымнар бүлекләр, бүлекчәләр буенча, чыгымнар төрләре буенча чыгымнар; чыганаклар төрләре буенча җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары; җирлек Советының 2021 елга (2021 елга һәм 2022 - 2023 еллар план чорына) әлеге проектны керткәнче, муниципаль бурыч алулар программасы, бурыч сәясәтенең төп юнәлешләре;

проектларны җирлек Советына керткәнче 2020 елга (2020 елга һәм 2021- 2022 еллар план чорына) җирлек бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында җирлек Советы карарлары проектларын;

җирлекләргә, әлеге пунктчада күрсәтелгән актларда финанс органы тәкъдимнәрен исәпкә алмыйча, җирлекнең тиешле вәкиллекле органына кертмәскә.

2. Бюджет консолидациясенә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

а) үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары белән расланган бюджетында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләр өлеше булган җирлек тарафыннан соңгы өч хисап финанс елының икесе дәвамында җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 5 процентыннан артыграк булуын үтәү;

б) муниципаль учреждениеләрнең срогы чыккан кредит бурычларын булдыруга юл куймау;

в) җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттырмауны, шулай ук җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары проектларын финанс органнарына Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү нәтиҗәсендә хезмәткәрләр санын арттыру кирәк булган очракта, алар кабул ителгәнче арттыру турында җирлекнең җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары проектларын финанс органына килештерүгә җибәрүне тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан дотацияләр керемнәре составына Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетында каралган күләмнәрдән артмаган күләмнәрдә җирлекләр бюджетларын раслау;

д) салым түләүләре буенча муниципаль районның берләштерелгән бюджетына бурычларны киметү буенча чаралар күрү;

е) муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан норматив финанслау принципларын үтәү;

ж) хезмәткә түләү фондын планлаштыруны исәпкә алып, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан, хезмәткәрләргә тарификация буенча исәпләнгән күләмнән ким булмаган күләмдә финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын формалаштыру.

3. Муниципаль финанслар белән идарә итү сыйфатын күтәрү кысаларында чараларны гамәлгә ашыру буенча йөкләмәләр:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясында билгеләнгән муниципаль бурычка алулар күләменә карата таләпләрне үтәү;

җирлек бюджеты турындагы карарда җирлек бюджеты кытлыгын финанслау чыганагы буларак каралган Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җәлеп итүгә планлаштырыла торган бюджет кредитлары булмау (җирле бюджетлар счетларында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредитларыннан тыш);

җирлекнең финанс органына тапшырыла торган бурыч кенәгәсе мәгълүматлары буенча җирлекнең бурыч йөкләмәләре буенча һәр айның 1нче числосына срогы чыккан бурычы булмау.

4. Әлеге исемлектә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән очракта, әлеге исемлектәге 1 пунктның «а» пунктчасында, 2 пунктның «а» пунктчасында, 3 пунктында каралган йөкләмәләрдән тыш, җирлекнең башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә, гамәлләре (гамәл кылмавы) күрсәтелгән йөкләмәләрне бозуга китергән җирлек җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затларына карата дисциплинар җаваплылык чараларын куллану бурычы йөкләнә.